**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О проведении русского народного праздника «Каравон»

В целях проведения в 2022 году русского народного праздника «Каравон» и на основании статьи 2 Закона Республики Татарстан от 19 февраля 1992 года № 1448-XII «О праздничных днях и памятных датах Республики Татарстан» **постановляю**:

1. С учетом предложений органов местного самоуправления и Министерства культуры Республики Татарстан провести русский народный праздник «Каравон» 28 мая 2022 года в селе Никольское Лаишевского района Республики Татарстан.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан, Министерству культуры Республики Татарстан оказать содействие в подготовке и проведении русского народного праздника «Каравон».

3. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» организовать освещение в средствах массовой информации подготовки и проведения русского народного праздника «Каравон».

4. Предложить органам местного самоуправления, общественным объединениям и организациям принять активное участие в подготовке и проведении русского народного праздника «Каравон».

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
16 мая 2022 года
№ УП-335

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында**

2022 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2022 елның 28 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 16 май
№ ПУ-335